РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАЙБЫЧ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

25.08.2023　　　　　　　　　　　　　　　　№ 1-76

"Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында"

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Кайбыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Кайбыч авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләр билгеләргә:

1) физик затның үлеменнән соң өч еллык срокның тәмамлануы яки аны гражданлык процессуаль законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителүе, әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаса, яки варисларның берсе дә мирас алудан читләштерелмәсә, яки варисларның берсе дә мирас алудан баш тартса, яки аларның барысы да мирас алудан баш тартса, һәм аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәсә;

2) салым түләүченең - гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада физик затның булуы;

3) мөлкәткә милек хокукы туктатылган көннән алып салым салу объекты булып торучы өч еллык срок узу;

4) гамәлдән чыгарылган җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү бурычы барлыкка килгән көннән соң өч ел вакыт узу.

2. Кайбыч авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип таныргa:

- «Җирле салымнар буенча недоимканы, әлеге салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре турында» 2022 елның 30 ноябрендәге 2-62 номерлы карары;

3. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Кайбыч авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　Нуретдинова С.И.